**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№1038**
**16.02.2021**

Башкарма комитетның «Законсыз сакланган яки табылган коралны, сугыш припасларын, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаучан матдәләрне ирекле рәвештә тапшырган өчен акчалата түләү турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 19 октябрендәге 5388 номерлы карары үз көчен югалтуны тану хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә коралның, сугыш припасларының, коралга патроннарның, шартлаткыч җайланмаларның һәм шартлаучан матдәләрнең законсыз әйләнештә йөрүен кисәтү чаралары турында» 1995 елның 5 августындагы 545 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 28 декабрендәге 1209 номерлы карары, шәһәр Уставының 42 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Законсыз сакланган яки табылган коралны, сугыш припасларын, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаучан матдәләрне ирекле рәвештә тапшырган өчен акчалата түләү турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 19 октябрендәге 5388 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге башлыгы Р.М. Мингалиевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов